КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1264

Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү һәм хезмәт базарының нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру чаралары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү һәм хезмәт базары нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү һәм хезмәт базары нәтиҗәлелеген арттыру» федераль

проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидия бирү өлешендә Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәте белән үзара бәйләнешләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» илкүләм проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү һәм хезмәт базарының нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2019 ел, 10 июнь, 481 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 декабрь, 1264 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү һәм хезмәт базары нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидия рәвешендә бирелә торган акчаны тоту кагыйдәләре

1. Бу Кагыйдәләр Татарстан Республикасында «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү һәм хезмәт базары нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итүче халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан субсидия (алга таба – Субсидия) рәвешендә бирелә торган акчаны тоту тәртибен билгели.

Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыру «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проекты составына керә торган «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү һәм хезмәт базары нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проектын тормышка ашыруда катнашучы Татарстан Республикасының аерым дәүләт халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте учреждениеләрендә гамәлгә ашырыла һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары эшчәнлеген оештыруга карата бердәм таләпләрне (алга таба – модернизацияләү проектлары, бердәм таләпләр тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре) кертүне күздә тота.

2. Субсидия Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) ачылган шәхси счетка керә.

3. Субсидияне тоту бу Кагыйдәләрнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм Субсидияне финанслауның иң чик күләмнәре турындагы

мәгълүматны Казначылыктан алган көннән җиде эш көне эчендә агымдагы финанс елына Субсидияне финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) җиткерә.

5. Министрлык агымдагы финанс елына Субсидияне финанслауның иң чик күләмнәре турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгыннан мәгълүмат алган көннән җиде эш көне эчендә агымдагы финанс елына финанслауның иң чик күләмнәрен агымдагы финанс елына Министрлык тарафыннан билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә модернизацияләү проектларын тормышка ашыра торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә җиткерә.

6. Бу Кагыйдәләрнең 5 нче пунктында күрсәтелгән субсидия халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренең нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән түбәндәге чараларын финанслау өчен модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә җибәрелә:

а) модернизацияләү проектларын тормышка ашыра торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре хезмәткәрләрен укыту;

б) модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре биналарына һәм бүлмәләренә агымдагы ремонт һәм капиталь ремонт ясау (Субсидия күләменнән иң күбе 67 процент);

в) модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре хезмәткәрләренең эш урыннарын уңайлылык дәрәҗәсен тәэмин итеп җиһазлау;

г) модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрен рәсмиләштерүнең фирма стилен кулланышка кертү, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чараларында модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә күрсәтелә торган хезмәтләр һәм ярдәм чаралары турында гражданнарга һәм эш бирүчеләргә мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән полиграфик продукция әзерләү; навигация чаралары, табличкалар һәм элмә такталар әзерләү һәм урнаштыру, модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре хезмәткәрләрен фирма киеме белән тәэмин итү;

д) сакчыл җитештерү принципларын һәм инструментларын кулланышка кертү, процессларны оптимальләштерү, гражданнарның тормыш хәлләрен һәм эш бирүчеләрнең бизнес хәлләрен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләрнең технологик схемаларын эшләү һәм кулланышка кертү;

е) Татарстан Республикасы территориясендә бердәм таләпләрне кулланышка кертүне һәм таратуны оештыру ягыннан һәм методик яктан тәэмин итү (шул исәптән модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре эшчәнлегенә җәлеп ителгән автоматлаштырылган мәгълүмат системаларын эшләүне, кулланышка кертүне һәм аларның эшчәнлеген оештыру-методик яктан тәэмин итүне кертеп), модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан кулланыла торган, Россия Федерациясенең мәгълүмат саклау өлкәсендәге законнары нигезендә сакланган элемтә каналларын булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү (аларны агымдагы карап тотудан тыш);

ж) модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне тикшерүдә тоту һәм аларның сыйфатын бәяләү системасын формалаштыру.

7. Модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, үзләренә билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә һәм аларның счетына бу Кагыйдәләрнең 5 нче пунктында күрсәтелгән акча керүгә карап, дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турындагы законнар таләпләре нигезендә бу Кагыйдәләрнең 6 нчы пункты белән күздә тотылган чараларны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында төзелгән дәүләт контрактлары (шартнамәләр) буенча товарлар (эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр) өчен түләүне гамәлгә ашыра.

8. Модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, хисап чорыннан соң килүче айның 11еннән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан расланган формалар буенча финанслашу максатларында Субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турындагы хисапны, Субсидиядән файдалану нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турындагы хисапны Министрлыкка тапшыра.

Министрлыкка тапшырыла торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә йөкләнә.

9. Министрлык, модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла торган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәте белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасын файдаланып әзерләнә (формалаштырыла) һәм төзелә торган Субсидия бирү турындагы килешүдә (алга таба – Субсидия бирү турындагы килешү) билгеләнгән Субсидиядән файдалану нәтиҗәләренә ирешү өчен җавап бирә.

10. Министрлык Субсидия бирү турындагы килешүгә теркәлгән кушымталардагы формалар буенча Хезмәт һәм халыкны эш белән тәэмин итү федераль хезмәтенә билгеләнгән вакытларда хисаплар тапшыра.

11. Субсидияне максатчан файдаланмау бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тарта.

12. Хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата Субсидиянең файдаланылмый калган өлешләре Россия Федерациясе бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

13. Субсидия бирү турындагы килешү белән күздә тотылган йөкләмәләр бозылган очракта, Субсидияне федераль бюджетка кире кайтару Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү турында» 2014 елның 30 сентябрендәге 999 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр формалаштыру, бирү һәм бүлү кагыйдәләре белән күздә тотылган тәртиптә һәм шартларда гамәлгә ашырыла.

14. Бу Кагыйдәләр нигезендә бирелгән акчаларны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

---